**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2023 елның 15 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Илексаз авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Илексаз авылында юл корылмаларын буяу өчен буяулар сатып алу, юл билгеләре салу;
- Илексаз авылы, Яшьләр урамы, авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш ташу);
- Илексаз торак пунктында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту (махсуслаштырылган техникага-МТЗ-82.1 тракторына хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу));
- җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын карап тоту (Илексаз авылындагы юлларны кардан чистарту);
- Илексаз авылында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар сатып алу);
- янгын куркынычсызлыгы өчен җиһазлар сатып алу (мотопомпа өчен запас частьләр, сулык өчен материаллар сатып алу);
- Илексаз торак пунктының янгын сулыклары дамбасын киңәйтү өчен туфрак ташу;
- юл кырыен кисү (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүче хезмәтенә түләү);
- Илексаз авылында күпләп ял итү урыннарын ремонтлау (материаллар, сәхнәләр сатып алу);
- Илексаздан һәйкәлләрне ремонтлау (материаллар сатып алу).

3. Әлеге карарны Илексаз авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Илексаз авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Гыйлфанов Гыйлфанов Ф.М